**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 27 сентябре № 56

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында»гы Бишнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 244 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның 2017 елның 13 июнендәге вн-5507-МР номерлы йөкләмәсен үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Салым кодексына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Бишнә авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Бишнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 244 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.7) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»гы 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтле махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001%.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыру Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**